**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«08» 05 2020 ел Яр Чаллы № 1625

Башкарма комитетның 2020 елның 10 мартындагы «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 741 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2016 елның 6 сентябрендәге Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 10 мартындагы 741 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләрен электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча йөртүдән җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатында оешмаларга Тукай муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»нә түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

8 пунктны: «Башкарма комитет субсидия алучының субсидия алу турында гаризасын кергән көнне терки һәм аны теркәгәннән соң ун эш көне эчендә документларның әлеге тәртип таләпләренә туры килүен тикшерә һәм субсидия бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Алучы әлеге Тәртипнең 2 һәм 5 пунктлары шартларына туры килүне тәэмин иткәндә, Башкарма комитет субсидия бирү турында карар кабул итә һәм карар кабул ителгәннән соң ун эш көне эчендә субсидия алучыга Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешма арасында төзелә торган килешү (шартнамә) проектының ике нөсхәсен җибәрә».

9 пунктны: «Субсидия бирү өчен нигез булып субсидия бирү мөмкинлеге турында карар һәм Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм оешма арасында төзелгән килешү (шартнамә) тора».

10 пунктны: «Субсидияләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан оешмаларның кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерелә. Субсидияләрне күчерү срогы – Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмаган вакытта».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов